ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

04 сентября 2020г.

**КАРАР**

№ 4374

Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең жирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Законы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 19 маендагы 2314 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУның Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4 - 2.8, 2.14, 2.17 статьяларында, 3.2 статьясының 3 һәм 4 бүлекләрендә, 3.3 - 3.8, 3.10, 3.16, 3.17 статьяларында күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:»;

2) 3 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.


2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 4 сентябрендәге
4374 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 19 маендагы
2314 номерлы карарына
3 нче кушымта




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева